Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге Советы

# КАРАР

**№ 8** **«21» октябрь 2025 ел**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының 2012 елның 26 июлендәге 60 номерлы «Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 февралендәге 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының 2012 елның 26 июлендәге 60 номерлы «Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 5 июнендәге 91 номерлы үзгәрешләр белән карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Нурлат муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге Советы Рәисе С.В. Белов